**Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы**
**Кәрәкәшле авыл җирлеге Советы**

КАРАР № 12

Кәрәкәшле ав. 6 нчы июль 2022 ел

2022 елның 31 гыйнварындагы Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Кәрәкәшле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру барышында кулланыла торган тикшерү кәгазе (контроль сораулар исемлеге) формасын раслау турында» 4 санлы Кәрәкәшле авыл җирлеге Советы карарын юкка чыгару турында

Россия Федерациясе Конституциясе, Россия Федерациясе Җир кодексы, 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль закон, 2020 елның 31 июлендәге «Россия Федерациясендә дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль турында»гы 248-ФЗ санлы Федераль закон, 2008 елның 26 декабрендәге «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында»гы 294-ФЗ санлы Федераль закон, 2021 елның 27 октябрендәге «Тикшерү кәгазьләре рәвешләре проектларын эшләүгә, эчтәлегенә, иҗтимагый тикшерүгә таләпләрне раслау, тикшерү кәгазьләрен раслау, куллану, актуальләштерү турында, шулай ук тикшерү кәгазьләрен мәҗбүри куллану очракларын раслау хакында»гы1844 санлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлеге Советының 2019 елның 17 июлендәге 10 санлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «Кәрәкәшле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Кәрәкәшле авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең гамәлдәге норматив хокукый актларын законнарга туры китерү сәбәпле, Ютазы муниципаль районының Кәрәкәшле авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. 2022 елның 31 гыйнварындагы Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Кәрәкәшле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү өлкәсендә муниципаль контрольне гамәлгә ашыру барышында кулланыла торган тикшерү кәгазе (контроль сораулар исемлеге) формасын раслау турында» 4 санлы Кәрәкәшле авыл җирлеге Советы карарын юкка чыгарырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Кәрәкәшле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә махсус мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасының Ютазы муниципаль районы сайтында «Рәсми Татарстан» дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм Порталы составында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми халыкка игълан ителгәннән бирле үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Кәрәкәшле авыл җирлеге башлыгы: А.Г.Дәүләтгәрәев